**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның 18 июленнән — № 58-447

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2025 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2024 елның 27 декабрендәге 51-396 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2025 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2024 елның 27 декабрендәге 51-396 номерлы карары белән расланган 2025 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2025 елда ачык аукционнарда сату юлы белән хосусыйлаштырылырга тиешле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан җир һәм мөлкәтләр исемлеген түбәндәге әчтәлектәге 4,5,6 пунктлар белән тулыландырырга:

| № т/б | Милек атамасы | Милекнең урнашу урыны | Мәйданы, кв. м. | Хосусыйлаштыруның планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 4 | FORD MONDEO 212300-55 җиңел автомобиле, д/н Х 435 РЕ 116 RUS, 2016 елда чыгарылган, VIN Z6FDXXEECDGG16201 | ТР, Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Ленин ур., 37 А й. | - | 2025 елның 3 кварталы |
| 5 | LADA KSOY5L җиңел автомобиле, д/н Х 840 РЕ 116 RUS, 2017 елда чыгарылган, | ТР, Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, | - | 2025 елның 3 кварталы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | VIN XTAKSOY5LJ1028816 | Ленин ур., 37 А й. | | |
| 6 | Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә ав., Парк ур., 12 й. адресы буенча урнашкан Ремонт остаханәсе торак булмаган бина, кадастр номеры 16:31:150106:130, гомуми мәйданы 318,4 кв.м. һәм 16:31:150106:398 кадастр номерлы җир кишәрлеге, гомуми мәйданы 377 кв.м. | Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Парк урамы, 12 й. | 318,4 | 2025 елның 3 кварталы |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасары Н.И. Попкова